КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 ноябрь г.Казань № 855

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кан донорлыгына ярдәм итү турында» 2014 ел, 5 июнь, 379 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кан донорлыгына ярдәм итү турында» 2014 ел, 5 июнь, 379 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бу карар нигезендә социаль яклау (ярдәм) чаралары күрсәтү, гарантияләр, акчалата түләүләр бирү турындагы мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (аннан алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 ел, 17 июль, ФЗ-178 нче Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла,

Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр, шулай ук гражданнар булып тора; гражданнарның мәгълүмат системасыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гамәлгә ашырыла.»,

әлеге карар белән расланган Донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләре тарафыннан ачык норматив йөкләмәләрне үтәү буенча Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкаләтләрен башкару һәм аларны гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибенең 5 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән кан һәм (яки) аның компонентларын биргән донорларга күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары, бирелгән гарантияләр, түләүләр турындагы мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә бирүне тәэмин итәргә.».

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\855.docx